**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 4 31 гыйнвар 2022 ел

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карары үз көчен 2022 елның 1 февраленнән югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат

стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Минһаҗев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
31.01.2022 ел, № 4

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2022 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2534,08 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1160,80 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3269,80 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6964,68** |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
31.01.2022 ел, № 4

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2022 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 263,94 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2270,14 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1160,80 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3269,80 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6964,68** |